РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 26 сентябре** **Чистай шәһәре** **№34/2**

Чистай шәһәр Советының
«Физик затлар мөлкәтенә
салым турында» 2015 елның
10 сентябрендәге 43/1 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 10 сентябрендәге 43/1 номерлы карарының 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктчаның икенче абзацында «, әлеге карарның 2 пунктындагы 7 пунктчасында каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.2. түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) 2025-2027 елларга карата 1,2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган күчемсез мөлкәт объектлары һәм алардагы урыннар;»,

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре Башлыгы Д. А. Иванов